# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

## КАРАРЫ

**№ 37** **19.07.2021 ел**

**«2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты турында» 2020 елның 10 декабрендәге 13 номерлы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты турында» 2020 елның 10 декабрендәге 13 номерлы Александр Бистәсе авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктында:

а) 1 өлештә «4441,3» санын «4947,3» санына алмаштырырга;

б) 2 өлештә «4456,3» санын «5203,7» санына алмаштырырга;

в) 3 өлештә «15,0» санын «256,4» санына алмаштырырга.

1.2. «2021 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтасының 1 таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.3. «2021 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре» 2 нче кушымтасының 1 таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

1.4. «2021 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 5 нче кушымтасының 1 таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.5. «2021 елга Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 6 нчы кушымтасының 1 таблицасына үзгәрешләр кертергә һәм әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Александр Бистәсе авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе** **Л.Г. Варганова**